**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2024 **Чирмешән авылы** №429

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Иске Үтәмеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2023 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 29 декабрендәге № 1743 карары белән расланган Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү һәм раслау, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәтләр бирү һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүленгән рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәтләр бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенең 2.8 пункты, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2021 елның 22 декабрендәге №80 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, **КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Иске Үтәмеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча кушымталар (Шәһәр төзелеше регламентлары, шәһәр төзелеше зоналаштыру картасы, Территориаль зоналар., Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналаштыру картасы, Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен куллану

тәртибе һәм күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү) нигезендә гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- гавами тыңлауларны оештыручы - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты;

- гавами тыңлауларны үткәрү вакыты - 2025 елның 09 гыйнварында 8.30 сәгатьтә.

- үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Чирмешән авылы, Совет ур., 32 йорт адресы буенча урнашкан район Советының конференц-залы.

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелергә мөмкин адрес - Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы:

- Чирмешән авылы, Совет урамы, 32 йорт - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге;

- Иске Үтәмеш авылы, М. Җәлил урамы, 52 йорт Иске Үтәмеш авыл җирлеге Башкарма комитеты.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре, түбәндәге составта гавами тыңлаулар үткәрү турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем төзергә:

Эш төркеме рәисе - Җамалетдинов Илнур Минсәгыйть улы, Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;

Эш төркеме рәисе урынбасары - Вилданов Муса Габделхак улы, Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары;

Эшче төркем әгъзалары:

Севастьянова Наталья Николаевна – Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;

Җиһаншина Эльвира Бурундай кызы - Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы;

Мингулов Рәфис Садыйр улы - Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авыл җирлеге башлыгы.

4. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәргәндә гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), 2024 елның 20 декабреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе Җамалетдинов И.М.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына кушымта
19.12.2024 ел №429

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының
Иске Үтәмеш авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре
проекты буенча гавами тыңлаулар үткәргәндә
гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча
фикер алышуда катнашу тәртибе

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларны үткәргәндә тәкъдимнәр Иске Үтәмеш авыл җирлеге Башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча кабул ителә (җибәрелә): Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Иске Үтәмеш авылы, М. Җәлил урамы, 52 йорт яисә Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегендә түбәндәге адрес буенча кабул ителә (җибәрелә): Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Чирмешән ав., Совет ур., 32, кушымта итеп бирелгән үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язма рәвештә:

| № | Тәкъдимнәр кертү инициаторы | Кертү датасы | Абзац, пункт, өлеш, статья | Проект тексты | Тәкъдим тексты | Кертелгән тәкъдимне исәпкә алып, проект тексты | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча язма рәвештә авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы күрсәтелгән тәкъдимнәр.

3. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Иске Үтәмеш авылы, М. Җәлил ур., 52 йорт, Иске Үтәмеш авыл җирлеге Башкарма комитетына яки түбәндәге адрес буенча урнашкан Чирмешән муниципаль районы инфраструктур үсеш бүлегенә: Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Чирмешән авылы, Совет ур., 32 йорт, шәхсән яисә почта аша (конвертта «җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты турында фикер алышу» яисә «гавами тыңлаулар» тамгасы белән), шулай ук (84396) 2-54-49 телефоны буенча.

4. Гражданнарның тәкъдимнәре Иске Үтәмеш авыл җирлеге Башкарма комитеты хезмәткәрләре, Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан теркәлә һәм карау өчен гавами тыңлаулар үткәрү буенча оештыру комитетына тапшырыла.